**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

КАРАР
от ____________

16.02.2022
ПР-31

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ ___________

"Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында 2020-2021 уку елына балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән яңа мәктәп автобус маршрутын ачу турында"

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларыннан нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 елның 03 августындагы 400 нче номерлы карарын үтәү йөзеннән, балаларны йөртү өчен кулланыла торган автобуслар белән укучыларны йөртүнең иминлеген тәэмин итү максатларында, КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә 2022 елның 15 февралендәгы мәктәп автобусларының хәрәкәт итү маршрутларын тикшерү акты нигезендә, 2022 елның 21 февраленнән түбәндәге автобус маршрутларын ачарга:

1.1. МБББУ "Аккуз төп гомуми белем бирү мәктәбе” – МБББУ “Меңнәр төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципальара махсус 14 нче номерлы мәктәп маршруты;

2. " Татавтодор" АҖ Минзәлә филиалының Актаныш ДРСУ башлыгына тәкъдим итәргә:

- юл хәрәкәте иминлеге таләпләре нигезендә автомобиль юлларын, укучыларны юл маршрутында утырту һәм төшерү пунктларын карап тотуны һәм ремонтлауны тәэмин итәргә;

- кышкы чорда юлларны даими чистартуны оештырырга.

3. Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- юл хәрәкәте иминлеге таләпләре нигезендә автомобиль юлларын, укучыларны юл маршрутында утырту һәм төшерү пунктларын карап тотуны һәм ремонтлауны тәэмин итәргә;

- кышкы чорда юлларны даими чистартуны оештырырга.

4. "Актаныш АТХ" МУП директорына тәкъдим итәргә:

- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МКУ белән килештерелгән автобус маршрутлары паспортларын һәм автобуслар хәрәкәте расписаниесен эшләргә һәмраслауга тапшырырга;

- мәктәп маршрутларын тикшерүнең рәсмиләштерелгән актларын тикшерү тәмамланганнан соң биш көн эчендә Башкарма комитет җитәкчесенә тапшырырга;



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

- расланган расписание нигезендә мәктәп автобусларын эксплуатацияләүне катгый тәэмин итү;

- инструктаж мәҗбүри үткәрелеп, кимендә 3 ел эш стажы булган машина йөртүчеләрне сайлап алуны тәэмин итәргә;

- мәктәп автобусларын эксплуатацияләү өчен җаваплы башкаручыларны билгеләү буенча боерык чыгарырга.

5. Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча ЮХИДИ бүлеге башлыгына тәкъдим итәргә:

- юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры китереп, күрсәтелгән маршрутлар буенча мәктәп автобусларының куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча катгый контроль оештырырга.

6. Гомуми белем бирү учреждениеләре директорларына:

- балаларны торак пунктлардан база мәктәбенә кадәр алып бару һәм кире кайтару өчен, балаларның исемлеген күрсәтеп, җаваплы укытучыларны (озатып йөрүче) билгеләргә. Ай саен озатып йөрүче укытучылар һәм укучылар белән мәҗбүри инструктажлар үткәрергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы Р.М.Шакировага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.А. Ильясов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 00C052E17911E828C3B7FDC5EC59E16D90
Владелец: Ильясов Рустем Алмазович
Действителен с 13.02.2022 до 09.05.2023

Лист согласования к документу № ПР-31 от 16.02.2022
Инициатор согласования: Тагирова А.А. Ведущий специалист
Согласование инициировано: 16.02.2022 09:38

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шакирова Р.М. | | Подписано 16.02.2022 - 09:39 | - |
| 2 | Ильясов Р.А. | | Перенаправлено 16.02.2022 - 13:19 | - |
| | **Перенаправление**(последовательное) | | | |
| | Нурлыева Л.Ф. | | Согласовано 16.02.2022 - 13:41 | - |
| 2.1 | Ильясов Р.А. | | Подписано 16.02.2022 - 14:35 | - |